СОВЕТ КИЛЬДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

11.01.16　　　　с. Кильдеево　　　　5-34

Килди авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст. карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 п. 1 пункты, Килди авыл җирлеге Уставының 11 ст. карары, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2015 елның 16 декабрендәге 4-28 номерлы Килди авыл җирлеге Советы карары, «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 2015 елның 16 декабрендәге 2 номерлы Килди авыл җирлеге башлыгы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Килди авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Килди авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2016 елның 6 мартына җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«2016 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчалар юлламасы белән риза булырсызмы:

- Килди авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә урнашкан зиратларны 110000 сумлык төзекләндерү: 900 метр озынлыктагы койма, керү төркемнәрен 3 данә итеп ясау.

ӘЙЕ　　　　　　　　ЮК".

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы

В. М. Бурдин